РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

25 гыйнвар 2023

№ 49

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының 2012 елның 2 февралендәге 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законына, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Федераль законның 19 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 29.12.2022 N 641-ФЗ номерлы Федераль законына нигезләнеп, Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының 2012 елның 2 февралендәге 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә::

«2.14п.«яисә тиешле белем бирү программасы буенча дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булу срогы тәмамлану» сүзләрен, «дәүләт аккредитациясе гамәлен туктату» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов